ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 ел 16 февраль**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 301**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының күпфатирлы йортларын авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында» 2011 елның 31 декабрендәге 2425 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2016 елның 15 июнендәге Татарстан Республикасы арбитраж суды Дело №А65-31440/2015 Карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының күпфатирлы йортларын авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында» 2011 елның 31 декабрендәге 2425 номерлы карарындагы кушымтадан «Зеленодольск шәһәре, Рогачев ур, 18 нче йорт» - 81 пунктны төшереп калдырырга.
2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлеге башлыгы А. Н. Коршуновка әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында һәм Интернет челтәренең Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең авария хәлендәге торактан гражданнарны күчерү программасын гамәлгә ашыру буенча урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин